РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 Буа шәһәре № 284/Бк/к

2024 елның III кварталына торак урынның
гомуми мәйданының бер квадрат метры
бәясе турында

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү «Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган аерым чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2024 елның II яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2024 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2024 елның 18 июнендәге 390 /пр боерыгы нигезендә,«Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2024 елның 8 июлендәге 202 номерлы тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проектын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның III кварталына яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Буа муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры нормативын 64327,00 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов